СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.01.2018 г.Агрыз № 24-1

2017 елда Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча бүлегенең оператив-хезмәт эшчәнлеге нәтиҗәләре турында

2017 елда Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча бүлеге башлыгының Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча бүлегенең оператив-хезмәт эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисабын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2017 елда Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча бүлегенең оператив-хезмәт эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисапны игътибарга алырга.
2. Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Әгерҗе районы буенча бүлегенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- җинаять һәм хокук бозуларны ачыклау, законсыз корал, наркотик һәм психотроп матдәләр, алкоголь продукциясе әйләнеше, су-биологик ресурсларын законсыз чыгару өлкәсендә эшчәнлекне дәвам итү.
- профилактик эшне, шул исәптән җинаятьләрнең превентив составларын ачыклау юлы белән, шулай ук өлкән яшьтәге кешеләргә карата кылынган мошенниклык очракларына юл куймау буенча активлаштырырга.
- хезмәт күрсәтү территориясендә Әгерҗе муниципаль районының террорчылыкка каршы комиссиясе утырышларында карау өчен мәсьәләләрне дә кертеп миграция вәзгыятен контрольдә тоту һәм экстремизм, терроризм күренешләрен булдырмау буенча эшне дәвам итәргә.
- җинаятьләрнең, шул исәптән узган елларда кылынган җинаятьләрнең ачылышын арттыру буенча чаралар күрергә.
- буйсынудагы шәхси составны, алга таба административ беркетмәләр төзеп, җәмәгать тәртибенә һәм җәмәгать иминлегенә йогынты ясый торган, ачыкланган административ хокук бозулар санын арттыруга юнәлдерергә.
- ирекле халык дружиналары эшенә үткәрелгән анализ нигезендә, Әгерҗе муниципаль районы башлыгына ай саен ДНД эше турында хәбәр итәргә.
- хезмәт күрсәтү территориясендә авариялелек күрсәткечләрен киметү буенча

өстәмә чаралар күрергә.

-күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты кимүгә юл куймаска.

3. Әлеге карарны PRAVO.TATARSTAN.RU Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районы мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының Законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча Даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет рәисе В. В. МАКАРОВ